*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2025-2026 нчы уку елы 4 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 50**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Нечкә сузыклардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   1) карлыган
   2) төнбоек
   3) зәңгәрсу
   4) тәмләткеч

2. Хатасыз язылган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) үнбишләп
2) алифба
3) төнлә
4) бедрә

3. *Яшел* сүзендә я хәрефе нинди аваз белдерүен билгеләгез. **(2 балл)**
1) [а] авазын
2) [йә] авазын
3) [йа] авазын
4) [ә] авазын

4. Юлдан-юлга күчерергә мөмкин булмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) апа
2) яңгыр
3) һөнәр
4) чәүкә

5. Җөмләдәге хәбәрне билгеләгез. **(2 балл)**
*Математика дәресендә бер мәсьәләне беркем дә, хәтта Лилия дә чишә алмады.*
1) дәресендә
2) чишә алмады
3) беркем дә
4) Лилия

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Тимерченең кулы кара, ...*
1) тире ага.
2) эше авыр.
3) икмәге ак.
4) юылмаган.

7. Синоним сүзләрне билгеләгез. **(2 балл)**
1) төз, туры
2) эшләү, ашау
3) сөйләшү, йоклау
4) яшь, карт

8. Эчтәлегенә карап, җөмләнең ахырын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Көзнең ачы җиле ...*
1) яфракларны куалады.
2) җир өстен ак карга күмде.
3) йөгереп килде.
4) бакчаны ак чәчәкләргә күмде.

9. *Әнием* сүзе юнәлеш килешендә кулланылган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
1) әниемә әйтү
2) әниемне көтү
3) әниемнең күлмәге
4) әниемнән ишетү

## II. Теоретик бирем.

Шигырьне укыгыз. Берлек сандагы 1 һәм 2 нче зат алмашлыкларын тиешле килештә куеп, сүзләр белән языгыз. Зат алмашлыклары турында белгәннәрегезне языгыз. (**10 балл**)

**(2 зат алмашлыгы) _________** җыр бар,

**(1 зат алмашлыгы) _________** җыр бар –

Матур җырлар бик күп җирдә.

Синең җырың миңа күчсен,

**(1 зат алмашлыгы) _________** җырым **(2 зат алмашлыгы)** ______күчсен –

Җырлыйк әле бергә-бергә (*Ф. Яруллин*)

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Фразеологик әйтелмә һәм аның мәгънәсен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) хәрәкәткә килү | 1) шәп белү |
| Ә) ут борчасы | 2) хәрәкәтчән |
| Б) су кебек эчү | 3) югалту |
| В) колак кагу | 4) ягымлы |
| Г) тәмле телле | 5) кузгалу |

**Җавап :** ________________________

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Шигырьне укыгыз һәм күп ноктлалар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(4 балл)**

М...нә ике көн инде
Үзем җыештырам өйне.
Буямагыз, белегез,
Бик сакланып йөр...гез.

Җил чыкса, тузан керер,
Ф...рточканы ачмагыз.
Үзем җы....штырдым өйне,
Чисталыкны саклагыз!

(Заһирә Гомәрова)

2. Шигырьнең икенче куплетыннан басым соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл)**

______________________________________________________________________

3. *Җил* сүзенә 4 тамырдаш сүз уйлап языгыз. **(4 балл)**

4. “Чисталыкны саклыйк!” темасына 6-7 җөмләдән торган инша языгыз. (**7 балл**)

*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2025-2026 нчы уку елы 5 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 58**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Аваз һәм хәрефләр саны туры килгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
  1) карлыган
  2) якты
  3) юынгыч
  4) биек

2. Ирен гармониясенә буйсынган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) беркатлы
2) төнбоек
3) күгәрчен
4) зыянлы

3. Җөмләдәге ябык иҗекләрдән генә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Очы-кырые күренмәгән болын уртасында зур бер күл булган. (А.Алиш)*
1) күренмәгән
2) болын
3) уртасында
4) булган

4. Хаталы язылган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) һөнәр
2) сөлге
3) рәссәм
4) игълан

5. **ь** билгесе аеру билгесе буларак кулланылган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) юньле
2) Ильяс
3) тирә-юнь
4) фигыль

6. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

***Алма** күп! Ләкин берсен дә*
*Сорамыйча **алма** син. (З.Нури)*
1) синоним сүзләр
2) антоним сүзләр
3) омоним сүзләр
4) күпмәгънәле сүз

7. Җөмләдәге ясалма сүз дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
*Бу елганың ике ярын да таллык камап алган*.
1) елганың
2) ярын
3) таллык
4) алган

8. Эчтәлегенә карап, җөмләнең ахырын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Биек тау битендә мәш килеп чана шуган балаларның .... .*
1) күңелләре моңсу.
2) йокысы килә.
3) шат авазлары ишетелә.
4) кайтып килгәнен күрәм.

9. Җөмләдә аерып бирелгән сүзнең кайсы сүз төркеменә каравын билгеләгез. **(2 балл)**
*Бакчадагы агачлар **күптән** яфракларын койганнар. (Д. Аппакова)*
1) исем
2) рәвеш
3) сыйфат
4) фигыль

10. Тиңдәш кисәкләре булган җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Алмаз бүген футбол уйнады.
2) Алмаз уйнады.
3) Бүген ул футбол, волейбол уйнады.
4) Дәрес бетте, без өйгә кайтып киттек.

## II. Теоретик бирем.

Шигырьне укыгыз. Аерып бирелгән 1 зат берлек сандагы фигыльләрнең тиешле кушымчаларын языгыз. Хикәя фигыль турында белгәннәрегезне языгыз. (**10 балл**)

Фәннәр **укы____** мәктәбемдә –

Тырышып белем **ал____**.

Туган телемне яратам,

Тукайны укып **бел**_____.

Беләсегез килсә, быел

Мин бишенчегә керәм.

Алдымда күпме мәсьәлә

Җавабын үзем чишәм.

Йолдызлар серен ачарга

**Чакыр**____ мине җиһан. (*Г. Гайнетдиновадан*)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Бирелгән сүзләргә берәр хәреф өстәп, тамырдаш сүз ясагыз, ул сүзләрне языгыз. **(5 балл)**

Тара- - ______________________________

Бизә- - _____________________________

Аш - _______________________________

Илә- - ______________________________

Ела**- -** ______________________________

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Фразеологик әйтелмә һәм аның мәгънәсен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) трай тибү | 1) ачулану |
| Ә) авызы колакка җитү | 2) эшләмәү |
| Б) пыр туздыру | 3) курку |
| В) күз буяу | 4) алдау |
| Г) хафага төшү | 5) шатлану |

**Җавап :** ________________________

2. Шигырьне укыгыз һәм күп ноктalar урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(4 балл)**

Алланып таңнарның алына,

Нур булып кешелек таңына,

Җыр булып үрелеп кү...елгә,

Кил безгә, Яңа ел, кил безгә!

Ко...шлы көннәрнең җылысын,

Бәхетнең, шатлыкның ол...сын

Күтәреп көннәрнең и...енә,

Рәхим ит Туган ил түренә! (*Э. Мөэминова*)

3. *Ко...шлы көннәрнең җылысын* юлындагы сүзләрне антонимнарына үзгәртеп языгыз. **(3 балл)**

---

4. Беренче куплеттан тамырдаш сүзләрне күчереп алыгыз, сүзләрнең тамырын шартлы билге белән күрсәтегез. **(3 балл)**

________________________________________________

5. “Нәрсә ул матурлык?” темасына 7-8 җөмләдән торган инша языгыз. (**8 балл**)

*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2025-2026 нчы уку елы 6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 57**

**I. Тест биремнәрен эшләгез.**

1. Җөмләдәге рәт гармониясенә буйсынмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

*Төркем булып йөзгән авыр болытлар бертуктаусыз куера бара.(А.Расих)*

1) төркем
2) йөзгән
3) бертуктаусыз
4) куера

2. Борын тартыклары дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

1) [г], [к], [ж]
2) [м], [н], [ң]
3) [һ], [л], [з]
4) [с], [ф], [ш]

3. Калын сузыклардан гына торган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**

1) Изгелек эшен озакка сузарга ярамый.
2) Инсафлының теле саф.
3) Тел күңелнең көзгесе.
4) Акылың булса, ачу саклама.

4. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

1) әмма
2) өстәлдәге
3) апаларыбызга
4) барганнар

5. Хаталы язылган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

1) маэмай
2) кәгазь
3) янгыр
4) палас

6. Җөмләдә аерып бирелгән сүзнең синонимын билгеләгез. **(2 балл)**

*Нәҗип **сандугачының** балалар чыгарганын күрми калды.*

1) кошчык

2) былбыл
3) карлыгач
4) һөдһөд

7. Эчтәлегенә карап, җөмләнең ахырын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Бүтән өмәләрдән аермалы буларак, каз өмәсе - .....*
1) казлар бәйрәме.
2) язын үткәрелә.
3) башыннан азагына кадәр кызлар өмәсе.
4) тиз тәмамлана.

8. Тезмә сүз күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
1) алъяпкыч
2) алтмыш
3) бака яфрагы
4) бер-ике

9. *Көчлерәк* сыйфатының дәрәҗәсен билгеләгез. **(2 балл)**
1) гади
2) кимлек
3) артыклык
4) чагыштыру

10. Эндәш сүз кулланылган җөмләне билгеләгез (тыныш билгеләре куелмаган). **(2 балл)**
1) Алсу Айдаровна балаларга татар телен укыта.
2) Алия белән Гөлназ бүген чана шуалар.
3) Гөлфия Мансуровна керергә ярыймы?
4) Балаларга өй эшен аңлаталар.

## II. Теоретик бирем.

Шигырьне укыгыз. Аерып бирелгән исемнәрнең тиешле кушымчаларын языгыз. Исемнең килеш белән төрләнеше турында белгәннәрегезне языгыз. **(10 балл)**

Мин **бәхет**_____ кайдан алырмын**,**
Туган **йорт**_______ китсәм **гомер**_____?
Таш булып мин җансыз калырмын,
Сүз югалыр минем **телем**________.
Бер көн артык миңа мең **елд**______,
Айда түгел, туган илемдә! (*Н. Дәүли*)

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

### III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Сүз ясалыш чылбырында төшеп калган сүзне языгыз. **(5 балл)**

Яшел – ________________, яшелчәче

Өмет – ________________, өметсезлек

Аш –____________________, ашлама

Сабыр – ________________, сабырсызлык

Бүл –___________________, бүлмәдәш

### IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Сүз һәм аның килеп чыгышы ягыннан төркемчәсен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) дизель | 1) рус алынмасы |
| Ә) салам | 2) төрки-татар сүзе |
| Б) абый | 3) фарсы алынмасы |
| В) мәдрәсә | 4) гарәп алынмасы |
| Г) җиһан | 5) Европа алынмасы |

**Җавап :** ______________________

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Кызык сезгә, яшь балалар, кышкы кичтә!
Җылы өйдә утырасыз якын мичкә;
Утырасыз рәхәтләнеп, т...зелешеп,—
Шатлык сезгә, уңайсызлык килми ....ич тә.
Һичкайсыгыз таныш түгел хәсрәт берлә,

Утыргансыз матур гына, рәт-рәт берлә;
Кышкы кичнең оз....нлыгын сизмисез дә
Ә...кәгезнең сөйләгәне әкият берлә. (*Г. Тукай*)

3. Шигырьдән антоним сүзләрне күчереп алыгыз, сүз төркемнәрен күрсәтегез. **(3 балл)**

___

4. *Берлә* сүзенең хәзерге татар телендәге сүзен языгыз. **(2 балл)**

___

5. “Кышкы кич” темасына 8-9 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)

___

*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен**
**татар теленнән республика олимпиадасының**
**муниципаль туры биремнәре**
**2025-2026 нчы уку елы**
**7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 64**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Җөмләдәге аваз чиратлашуы дөрес күрсәтелгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Күке җитене бизи язгы урманны, матурлыгы белән карашыбызны җәлеп итә.(М. Рафиков)*
1) җитене
2) язгы
3) матурлыгы
4) карашыбызны

2. Яңгырау тартык авазлар гына кергән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) шәһәребез
2) дөньядагы
3) авылдашлар
4) балакайлар

3. Антоним сүзләр кулланылган җөмләне билгеләгез. (**2 балл**)
1) Ак күл күзгә кебек шома боз белән капланган иде.
2) Алар, кәшәкә сыман таякларын алып, күлгә таба йөгерделәр.
3) Бозлар арасында, бер батып, бер калкып, кунак кызыбызның башы гына күренгәли иде.
4) Абдулла, әкрен генә артка таба шуып, кызны боз өстенә тартып та чыгарды.

4. Эчтәлегенә карап, җөмләнең ахырын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Дөнья шулай шул ул, балам, үзең егылсаң да еламыйсың,......*
1) бары тик көләсең.
2) торасың да китәсең.
3) авыртуга да түзәсең.
4) бу – яхшы күренеш.

5. Орфографик хатасы булган сүзне табыгыз **(2 балл).**
1) нигезсез
2) алдыңгы
3) мәхәббәт
4) каһарман

6. Сүзтезмәнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Алдан бишенче*
1) фигыльле сан сүзтезмә
2) санлы рәвеш сүзтезмә
3) исемле сан сүзтезмә
4) санлы исем сүзтезмә

7. Ясалма сүз кулланылган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**
1) Батыр үз халкын яклый.
2) Батырга яра да килешә.
3) Батырлыкта матурлык.
4) Батыр кеше бакыр өзәр.

8. Тартым белән төрләнгән исемнәр рәтен билгеләгез. **(2 балл)**
1) кош, кошчык, кошлар
2) алма, алманың, алмага
3) әнием, китабы, хатларың
4) дәфтәрләр, чишмәләр, күлләр

9. Җөмләдә куелырга тиешле тыныш билгесен билгеләгез. **(2 балл)**
*Кырым халкы кар бураннарын  суыкларны белми.*
1) өтер
2) ике нокта
3) сызык
4) нокта

10. Җөмләдә аерып бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге булуын билгеләгез. **(2 балл)**
*Ул кичне авылдан аеруча* ***күңелсез*** *хәбәр килде.*
1) аергыч
2) хәл
3) хәбәр
4) тәмамлык

### II. Теоретик бирем.

Искергән сүзләр турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**8 балл**)

____________________________________________________________________________

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Мәкальләрнең ахырын  уйлап языгыз. **(5 балл)**

1) *Өең кысан булса да,* ______________________________.
2) *Яхшы тел –* ______________________________.
3) *Сөйдергән дә – тел,* ______________________________.
4) *Баканың да* ______________________________ .
5) *Өйрәнгән* ______________________________.

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Тексттагы <... > тамгасы урынына тиешле тыныш билгеләрен куегыз. **(7 балл)**

Март ахыры якынлашкач <... >  беренче зур яңалык шул булды <... > кычыткан күбәләге оча башлады. Кирпеч төсле кызыл күбәләк. Шул кызыл өстендә вак кара таплар күренә. Юка канатлары читеннән кара кайма киткән <... >  ә каймага зәңгәр таплар тезелгән. Күбәләк суыкны агач ярыгында уздырган һәм яз җиткәч уянган.

Бераздан үрмәкүчләр уянды <... >  кайберләре кар өстендә сәяхәт итә башлады. Иртән кояш күренә <... >  үрмәкүч терелә <... > кичен суыта <... >  ул тагы үлеп куя. (*Г. Хәсәнов*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Татлы тәм бар ипекәйдә.
Төш....ндем мин яши-яши:
Кеше аңа үз ө....ндә
Сөенечен кушып ашый.
Ачы тәм бар ипекәйдә.

Карусыз гом...р юлдашы:
Шуның өчен аңа кеше
Кө....нечен кушып ашый. (*Р. Зәйдулла*)

3. *Ачы тәм бар ипекәйдә.* җөмләсенә синтаксик анализ ясагыз. (**4 балл**)

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

4. Шигырьдән антоним парларны күчереп языгыз, сүзләрнең кайсы сүз төркемнәренә каравын билгеләгез. (**4 балл**)

________________________________________________________________________

5. Шигырьдән үткән заман хикәя фигыльне табып языгыз, морфологик анализ ясагыз. **(3 балл)**

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

6. Сөйләм теленә хас сүзне күчереп алыгыз. **(2 балл)**

______________________________________________________________________

7. “Икмәк кадере” темасына 8-9 җөмләдән торган инша языгыз. (**9 балл**)

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2025-2026 нчы уку елы 8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 60**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Рәт гармониясе сакланмаган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   1) караңгы, әнкәй, алдынгы
   2) әлеге, тигез, җан
   3) фанилык, календарь, зәңгәрсу
   4) бураннар, урманнан, көннәр

2. Һәр сүздә дә [к] авазы әйтелә торган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   1) көл, кәккүк, каты, түгәрәк
   2) колын, ачкыч, казлар, камыш
   3) күңел, кыяр, кәбестә, коңгырт
   4) көзге, көн, караңгы, келәт

3. Җөмләдәге хаталы сүз дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
*Беркадәр тынычлангач, ул Якубка көтелмәгән тәкьдим ясады.*
   1) беркадәр
   2) тынычлангач
   3) көтелмәгән
   4) тәкьдим

4. Эчтәлегенә карап, җөмләнең ахырын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Тормыш өзлексез көрәштән гыйбарәт:..... .*
   1) көн дә эшләргә кирәк.
   2) торасың да китәсең.
   3) көчлеләр ега, көчсезләр егыла.
   4) көрәшү кирәк.

5. Фарсы теленнән алынган кушымча булган сүзләр рәтен билгеләгез. **(2 балл)**
   1) даруханә, хәбәрдар
   2) мәктәп, әдәбият
   3) чәчәкле, сәламәтлек
   4) цивилизация, механизм

6. Җөмләдә *йөгән* сүзенең мәгънәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2**

**балл)**

*Атларын йөгән тезгененнән җитәкләп, печәнчеләрнең бер-бер артлы күпер аша чыгуы сәгатьтән артыкка сузылды (Н.Әхмәдиев).*

1) берәр нәрсә эшләүдән тыю, тоткарлый торган сәбәп
2) нәрсәгә дә булса җитәкчелек итү
3) әдәпсезлек, тыйнаксызлык
4 ) атның башына кидерелә торган авызлыклы, тезгенле җайланма

7. Иярчен җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Үзегез күрәсез:бер тамчы яңгыр яуган юк. (Ш. Камал)*

1) иярчен аергыч җөмлә
2) иярчен ия җөмлә
3) иярчен тәмамлык җөмлә
4) иярчен вакыт җөмлә

8. Җөмләдәге алмашлыкларның төркемчәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Кем идем димә, кем булырмын диген!* (Мәкаль)

1) зат алмашлыгы
2) сорау алмашлыгы
3) күрсәтү алмашлыгы
4) билгесезлек алмашлыгы

9. Сүзтезмәләр арасыннан фигыль сүзтезмәне билгеләгез. **(2 балл)**

1) безнең халык
2) быел кышын
3) хезмәте белән мактаулы
4) өстәл өстенә кую

10. *Ул - бурычын бишләтә кайтара торган кеше*. җөмләсендәге *бишләтә* сүзенең нинди сүз төркеменә каравын язгыз. **(2 балл)**

Җавап: ____________

## II. Теоретик бирем.

Сузык авазлар өлкәсендә очрый торган аваз үзгәрешләре турында язгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**8 балл**)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
______________________________________________________________________

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Сүз һәм андагы басымның урынын тәңгәллек белән күрсәтегез**,** җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| СҮЗ | БАСЫМ УРЫНЫ |
|---|---|
| А) пәрәмәч | 1) икенче иҗектә |
| Ә) бирешмәскә | 2) өченче иҗектә |
| Б) кайчаннан | 3) беренче иҗектә |
| В) кырмыскалар | 4) дүртенче иҗектә |
| Г) чишелешендә | 5) бишенче иҗек |

**Җавап :** ________________________

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Мәкальләрнең ахырын уйлап языгыз. **(5 балл)**

*Егет сүзе* _____________________________________________________.

*Бер – алдыңа,* ____________________________________________________.

*Аз сөйлә,*__________________________________________________________.

*Җиде кат үлчә,* ___________________________________________________ .

*Туры әйткән – котылган,* ____________________________________________.

2. Тексттны укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Мин үзем икмәкне кеше өчен иң зарури ризык итеп кенә түгел, ә илнең иң зур байлыгы, дәүләтнең төп к...эте дип тә саныйм. Чыннан да, илдә, дәүләт кулында икмәк җитәрлек булмаса, халык тук, бөтен яши алыр идемени, дәүләт башка байлыкларын бүтән ихт...яҗларга тота алыр идемени?..

Халык икмәкнең дәрәҗәсен кытлык елларда гына түгел, ...әрвакытта, иң уңган чакларында да бик яхшы белгән. Ул аны юкка-барга әрәм-шәрәм

итмәгән, саклап тоткан, ничек тә запас белән торырга тырышкан. Безнең татар халкында исә икмәккә хөрмәт аеруча зур иде. “Ипекәй” дип к...дерләп кенә йөртә иде ул аны... (*Әмирхан Еникидән*)

3. Текстта антонимик парлы сүзне күчереп языгыз. (**2 балл**)

______________________________________________________________________

4. *Байлыкларын* сүзен мәгънәле кисәкләргә аерып языгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**4 балл**)

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

5. *“Ипекәй” дип к...дерләп кенә йөртә иде ул аны*... җөмләсендәге сүзләрне туры тәртипкә куеп языгыз. **(2 балл)**

______________________________________________________________________

6. Тексттан рус алынмасын күчереп языгыз. **(2 балл)**

______________________________________________________________________

7. *“Азның кадерен белмәгән күпнең кадерен белмәс”* темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре**
**2025-2026 нчы уку елы**
**9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 66**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Сүзләрнең язылышы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
1) мәнфәгат, тамам
2) мәнфәгать, тәмам
3) мәнфагать, тәмәм
4) манфагат, тамам

2. *Ачкыч* сүзенең мәгънәсе башкалардан аерылып торган рәтне билгеләгез. (**2 балл)**.
1) Мин балага шәхес итеп карыйм, күңеленә ачкыч табарга тырышам.
2) Менә сиңа ачкыч – өске йозакныкы.
3) Ул бишмәт кесәсеннән бер бәйләм ачкыч чыгарды.
4) Йорт бөтен кирәк-яраклар белән җиһазландырылган, ачкыч алып кер дә яшә.

3. Җөмләдәге борын ассимиляциясе күзәтелгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
*Кардәшләрнең игене күрше игеннәрдән кат-кат артык иде. (Дәрдемәнд)*
1) кардәшләрнең
2) игене
3) күрше
4) игеннәрдән

4. *Кояш - көне, ай төнне яктыртыр.* мәкалендә кулланылган сүзләрне билгеләгез. **(2 балл)**
1) мәгънәдәш сүзләр
2) аваздаш сүзләр
3) тамырдаш сүзләр
4) капма-каршы мәгънәле сүзләр

5. Җөмләдә <...> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен билгеләгез. **(2 балл)**
*Хәтер <...> еллар аша кайта торган изге матурлык иле.* (М. Госманов)
1) ике нокта
2) нокталы өтер

3) өтер
4) сызык

6. Эчтәлегенә карап, җөмләнең ахырын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Синең төп тәрбия ысулың хезмәт иде, авылым,.....* .
1) минемчә.
2) ул хәзер дә шулай булып кала.
3) мин ялгашканмын.
4) син укыттың безне.

7. Киләчәк заман хикәя фигыль кушымчасы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
1) гөрелдә - р
2) йөре - р
3) чүп -ләр
4) кит-ерер

8. *һәммәсе бишәү* сүзтезмәсенең төрен билгеләгез. **(2 балл)**
1) рәвешле сан сүзтезмә
2) санлы рәвеш сүзтезмә
3) алмашлыклы сан сүзтезмә
4) санлы исем сүзтезмә

9. *Әни җыры* **< ... >** *дөньядагы иң бөек җыр*. җөмләсендә <...> тамгасы урынына нинди тыныш билгесе куелырга тиешлеген языгыз. **(2 балл)**
Җавап: ____ _________

10. *Очраклы бер хәл аңа бу авыр мәсьәләне чишәргә ярдәм итте*. җөмләсеннән туры тәмамлыкны күчереп языгыз. **(2 балл)**
Җавап: ______________

## II. Теоретик бирем.

Тартыклар охшашлануы турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**8 балл**)

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Фигыльләр һәм аларның төркемчәләрен тәңгәллек белән күрсәтегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| ФИГЫЛЬ | ТӨРКЕМЧӘСЕ |
|---|---|
| А) соңлаган яз | 1) исем фигыль |
| Ә) урындыкка утыру | 2) хәл фигыль |
| Б) уйлар таралгач | 3) хикәя фигыль |
| В) куелмаган иде | 4) сыйфат фигыль |
| Г) әйткән булса | 5) шарт фигыль |

**Җавап :** ___________________

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Фразеологик әйтелмә барлыкка килерлек итеп, фигыльләр өстәп языгыз. **(5 балл)**

Борчак __________________________________

Кызыл кар ________________________________

Балтасы суга _____________________________

Трай ____________________________________

Тетмәсен_________________________________

**Җавап :** ______________________

2. Тексттны укыгыз һәм <...> тамгасы урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

1) Авылның үзенә генә хас тавышлар белән тулган изге тынлыгын бернинди бөек симфонияләр, моңлы көйләр дә уза алмый. 2) Бөтенесе йөрәккә якын, бөтенесе якты нур белән, ила<...>и тынлык, куанычлы моң белән өр<...>телгән. 3) Шуңа күрә авыл кешесенең шатлык-куанычлары да мәңге онытылмаслык, борчу-газаплары да йөрәген сулкылдатырлык тирән. 4) Әгәр шулай булмаса, авылыннан китеп, чит-ят җирләрдә гомер кичерүче кешеләр аны хәтерләреннән жуяр иде. 5) Юк шул, оныта алмый <...>дәм баласы туган төбәген. 6) Аның хәтерендә ялан тәпи баскан чирәмле ишегалды, аунап-тәгәрәп үскән болыннары, су кое<...>ган күлләре, челтерәп аккан чишмә

суларының тәмнәре, җиләк-җимеш тулы әрәмәләре, ап-ак кышлары торган саен жетерәк, дулкынландыргычрак булып яңара. (*Ф. Садриев*)

3. Тексттан Европа алынмасын табып, күчереп языгыз. **(2 балл)**

___

4. Тексттан синонимик парлы сүзләрне күчереп языгыз, кайсы сүз төркеменә карауларын билгеләгез. **(4 балл)**

___

___

5. 5-6 нчы җөмләләрдән әдәби нормадан читләшкән сүзне күчереп языгыз. (**2 балл**) ___

6. Тексттан *тын* сүзенә тамырдаш сүзне табыгыз, үзегез тагын ике тамырдаш сүз уйлап языгыз. (**3 балл**)

___

___

7. Бишенче җөмләне туры тәртипкә үзгәртеп языгыз. **(5 балл)**

___

8.“*Авылым иртәсе*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)

___

___

___

___

___

___

___

___

___

___

___

___

___

___

*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2025-2026 нчы уку елы 10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 63**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Күп нокталар урынына *х* хәрефе язылырга тиешле очракны билгеләгез. **(2 балл)**
1) ка...арман, ...ава
2) бини...ая, ни...аять
3) ...әр, Ил...ам
4) бә...әс, а...ыр

2. Морфологик принципка буйсынып язылган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) өстәлдә
2) телевизорның
3) китапларда
4) томанлы

3. Җөмләдәге *тагу* сүзенең мәгънәсе дөрес күрсәтелгән очракны билгеләгез. **(2 балл)**
*Ул минем айгырымның муенына шул кызыл тасма белән кыңгырауны такты.*
1) ияртү, җитәкләү
2) нәрсәнедер көчләп бирү, тапшыру
3) нәрсәнедер бәйләп, беркетеп кую
4) нәрсәнедер чәнчеп, эләктереп кую

4. Эчтәлегенә карап, җөмләнең ахырын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Әгәр үзеңдә ихтыяр көчең булмаса, ..... .*
1) нииндидер бер җитди эшне ахыргача җиткерү шикле.
2) башкалардан кара.
3) тырышу файдасыз.
4) эшләргә кирәк.

5. Барлыкта, берлек сандагы билгеле үткән заман хикәя фигыль кулланылган җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

1) Өй эченә, ишегалларына машина фараларыннан төшкән ут көлтәләре бөркелә.
2) Җылы кунмаган котсыз бу йортта хәтта чикерткә дә сайрамый.
3) Мин Зөләйха әбигә чәй кайнатып эчердем.
4) Имән яфраклары гына күзге җилгә бирешмәде.

6. Фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

1) Өлкән сержант Зариповның кабул итү имтиханнарына җибәрүне сорап язган рапортына колак салдылар.
2) Татарстан башкаласына кайтып төшкәч, озак кына ышанмый торды хәтта.
3) Гыйззәтнең хәрби частьтан алып килгән характеристикасын ошаттылар.
4) Уң якта бүтән факультетлар стенды янында торган кызлар кычкырып көлеп җибәрде.

7. *Ул әйләнә-тирә мохитне бик сизгер кабул итү, хәтер, фикерләү һәм ихтыяр көче белән тыгыз бәйләнгән*. җөмләсенең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

1) гади, җәенке, тулы, бер составлы хикәя җөмлә
2) гади, җәенке, тулы, ике составлы, хикәя җөмлә
3) гади, җыйнак, тулы, ике составлы, хикәя җөмлә
4) тезмә кушма җөмлә

8. Аналитик иярчен җөмлә белән баш җөмлә арасына ике нокта куелырга тиешле җөмләне билгеләгез (тыныш билгеләре куелмаган). **(2 балл)**

1) Бүген үк алып кайтыгыз юкса соңга калабыз.
2) Бу китапны укыгач шуны аңладым әсәр төгәл сюжетка корылмаган икән.
3) Һәркемгә мәгълүм ки илне хуҗасызлык тарката.
4) Кем тырыша аны һәркем ярата.

9. *Юлда барганда абый үзенең ерактан килүен<...> безнең калада әле беренче тапкыр гына булуын әйтте.* җөмләсендә <...> тамгасы урынына нинди тыныш билгесе куелырга тиешлеген языгыз. **(2 балл)**
Җавап: ______________________________

10. Билгеләү алмашлыгын күчереп языгыз: *кемнең, һичкайда, үз, алар, шушы* **(2 балл)**
Җавап: ______________________________

## II. Теоретик бирем.

Татар теленең орфографик принциплары турында языгыз, мисаллар китерегез. **(8 балл)**

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Синоним сүзләрне үзара тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) шыту | 1) җай |
| Б) тойгы | 2) гамьсез |
| В) форсат | 3) җан |
| Г) кот | 4) хис |
| Д) ваемсыз | 5) тишелү |

**Җавап : ________________________**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Бирелгән сүзләрнең тамырын языгыз. **(5 балл)**

Җәмгатьчелек – ________________________

Сырганак – ______________________________

Караңгы – ________________________________

Тартма – _________________________________

Аңлаешлы – ______________________________

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(1 балл)**

Ниләр диеп мин аңлатыйм икән
Шушы сәер, иләс чагымны?
Хәреф төртсәң, шигыр... үсеп чыгар -
Шундый чагы әле җанымның...

Вето салдым барлык мескенлеккә!
Җитте! Оят ап-ак бол...ттан!
Яшәү дигән тантанага бит без
Вакытлыча гына юлыккан... (*Зөлфәт*)

3. *Вето* сүзенең татар телендә кулланыла торган ике синонимын языгыз. **(2 балл)**

____________________________________________________________________________

4. *Иләс* сүзенең мәгънәсен аңлатып языгыз. (**3 балл**)

____________________________________________________________________________

5. *Мескенлеккә* сүзен мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**5 балл**)

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

6. Шигырьдәге *юлыккан* сүзенең транскрипциясен языгыз, фонетик анализ ясагыз. **(2 балл)**

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

7. Шигырьдән артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатны күчереп языгыз. **(2 балл)**

________________________________________________________________

8.“ *Игелекле эш*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)

________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________
________________________________________________________________

*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре 2025-2026 нчы уку елы 11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**

**Максималь балл – 67**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Татар теленең орфографик нормаларына туры килмәгән сүз язылган җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

1) Көннәр кояшлы торса да, көз инде үз көченә кергән.
2) Дөньяда җитмеш ел яшәгән Таҗетдин карт әкрен генә урыныннан торды да өяңке төбенә килде.
3) Кыз, ятьмәгә эләккән балыктай бәргәләнгән, тәмам адашкан.
4) Җил булмаса да, каеннар алтын яфракларын ташлап утыралар.

2. Җөмләдәге *таза* сүзенең мәгънәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Хәйдәр баштагы көннәрдә гел шунда чокынды, эшкә ярардай, таза такталарны җилкәсенә күтәреп ихатага ташыды. (В. Имамов)*

1) чиста, чүпсез
2) ныклы, көчле
3) ихлас
4) юан, көр

3. *Алар безгә кадәр йөз, биш йөз, мең ел элек яшәсәләр дә, бөтенләй юкка чыкмаганнар*. Җөмләсендәге *чыкмаганнар* сүзенең басымы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

1) чЫкмаганнар
2) чыкмАганнар
3) чыкмагАннар
4) чыкмаганнАр

4. Эчтәлегенә карап, җөмләнең ахырын дөрес билгеләгез. (2 балл)

*Кайчандыр балта остазының өйрәнчеге генә булып тагылып йөргән Хәлим .....*

1) ниндидер бер җитди эшне ахыргача җиткерергә тели.

2) хәзер әнә ничек оста уйната агачны, ничек бирелеп эшли эшен.
3) бүген ял итә.
4) хәзер дә бу шөгылен ташламады.

5. Искергән сүз булган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
1) йөзек кашы
2) уйлап баксаң
3) матбугат барлыкка килә
4) маңлаемнан сыйпады

6. Алынма сүзләргә дөрес кушымча ялганган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
1) автомагистраленә
2) автомагистральенә
3) автомагистралына
4) автомагистралена

7. Җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**
*Көн эссе булса да, Хәдичәттәй яшел ефәк шәл бөркәнгән, шәл чуклары җиргә кадәр салынган.*
1) теркәгечсез тезмә кушма җөмлә
2) теркәгечле тезмә кушма җөмлә
3) катнаш кушма җөмлә
4) синтетик иярченле кушма җөмлә

8. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең кайсы сүз төркеменә караганлыгын билгеләгез. **(2 балл)**
***Бу*** *сүзләр миңа шулкадәр көчле тәэсир иткән, күрәсең,* ***ул минем*** *бик нык исемдә калган.*
1) фигыль
2) алмашлык
3) исем
4) рәвеш

9. Җөмләдәге ясалма исемне күчереп языгыз. **(2 балл)**
*Авырлыклар очраса да каушап калмый, үзең салган сукмактан алга, бары тик алга гына атлау өчен рухи көч кирәк.*
Җавап: ________________________________________________

10. Җөмләдәге аерымланган хәлнең төрен языгыз. **(2 балл)**
*Эшләрнең барышы белән танышырга дип, Гөлзифа идарәгә юнәлде. (Р. Төхфәтуллин)*

Җавап: _____________

## II. Теоретик бирем.

Тезмә кушма җөмлә турында языгыз, мисаллар китерегез. (**8 балл**)

_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________
_______________________________________________________________

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Фразеологизмнар һәм аларның мәгънәләре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) ата йорты | 1) ял итеп алу |
| Ә) бәлеш авыз | 2) үч саклау |
| Б) баш кую | 3) хәтере тиз калучан кеше |
| В) үпкә бәлеше | 4) елак бала |
| Г) кинә тоту | 5) ватан |

**Җавап:________________________**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Бирелгән сүзләрнең тамырын языгыз. **(5 балл)**

Безелдәвек – ________________________

Тузганак – __________________________

Киселмәле – ________________________

Кадак – ____________________________

Аңлаешсызлык – ___________________

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(1 балл)**

«Сул аягың җиргә ныклап терә,
Чыбыркыңны уң кулыңа, ипләп…»
Көтүлектә шартлый кыюсыз чаң,
Г...ләм хәтеренә аваз киртләп.
Тагын, тагын… Елан төсл... ыслап,
Чыелдатып шартлый чыбыркым ла.
Мин җәйләүдә. Мин көтүче бүген.
Әткәм чыбыркысы <....> минем кулда! (*Л. Гыйбадуллинадан*)

3. *Әткәм чыбыркысы* <....> *минем кулда!* җөмләсендә <....> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**

4. Шигырьдән аваз ияртемнәреннән ясалган сүзләрне күчереп языгыз, сүз төркемен һәм аның төркемчәсен билгеләгез. (**3 балл**)

5. Беренче дүртьюллыктан тартымлы исемнәрне күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**5 балл**)

6. *Г...ләм хәтеренә аваз киртләп* җөмләсендәге *киртләп* сүзен ничек аңлыйсыз? Үз сүзләрегез белән аңлатып языгыз. **(3 балл)**

7. *Елан төсл... ыслап,Чыелдатып шартлый чыбыркым ла.* җөмләсенә синтаксик анализ ясагыз. **(5 балл)**

8.“*Авылым хәтирәләре*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)